Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР №XXXV-7**

Балык Бистәсе штп. 2023 елның 6 апреле

“Авыл хуҗалыгы җирләрен хосусыйлаштыру вакытына билгеләнгән җир кишәрлекләрен гражданнарга бушлай тапшыруның уртача район нормасы турында” 2021 елның 31 августындагы XI-1 номерлы Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы карарының үз көчен югалтуын тану хакында

“Татарстан Республикасы Җир кодексының 34 һәм 40 маддәләренә үзгәрешләр кертү турында” 2022 елның 29 сентябрендәге 54-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы үз көченә керүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. “Авыл хуҗалыгы җирләрен хосусыйлаштыру вакытына билгеләнгән җир кишәрлекләрен гражданнарга бушлай тапшыруның уртача район нормасы турында” 2021 елның 31 августындагы XI-1 номерлы Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.
3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы Р.Р. Ислямов